РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЧУВАШСКО-КИЩАКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЧУАШ КИШТӘГЕ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.06.2020 № 5

Буа муниципаль районының Чуаш Киштәге авыл җирлеге Башкарма комитетының 2016 елның 13 декабрендәге 12 номерлы карары белән расланган «Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге авыл җирлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе»нә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2009 елның 27 декабрендәге 365-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законнар, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон нигезендә Буа муниципаль районының Чуаш Киштәге авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Буа муниципаль районының Чуаш Киштәге авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 13 декабрендәге 12 номерлы карары белән расланган «Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге авыл җирлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе»нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә ( алга таба- Тәртип):

- Тәртипнең 2 бүлеге 2.2 пунктының «д» пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә расларга: «дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күп функцияле үзәк, оешмалар, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләр, хезмәткәрләр карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять бирүнең судка кадәр (судтан тыш) тәртибе.»;
- Тәртипнең 1 бүлеге 1.2 пунктының 3 абзацын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә расларга: « җирле үзидарә органы (алга таба - муниципаль хезмәт) тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәт - җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыру эшчәнлеге (алга таба - муниципаль хезмәтләр күрсәтүче орган), ул җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтүче орган вәкаләтләре чикләрендә мөрәҗәгать итүчеләрнең мөрәҗәгатьләре буенча гамәлгә ашырыла, ул “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм муниципаль берәмлекләр уставлары нигезендә, шулай ук “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә каралмаган мәсьәләләрне, җирле үзидарә органнарының башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда катнашу хокукларын хәл итүгә хокукларын билгеләгән очракта, әгәр бу федераль законнарда, җирле үзидарә органнарының башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә каралмаган һәм аларның федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектлары законнары

белән үз компетенцияләреннән төшереп калдырмаган башка мәсьәләләрне хәл итүгә хокуклары чикләрендә, мондый хокукларны гамәлгә ашыру турында муниципаль хокукый актлар кабул ителгән очракта;

- 2.9 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, күп функцияле үзәк, оешмалар карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять белдерү тәртибенә кагылышлы бүлектә "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаять белдерү тәртибенә кагылышлы бүлектә, шулай ук аларның вазыйфаи затлары, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләр, хезмәткәрләр күрсәтелә:

а) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) мөрәҗәгать итүче тарафыннан судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү предметы, шулай ук "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1_1 өлешендә каралган оешмаларга яисә аларның хезмәткәрләренә;

б) шикаять бирү һәм карау тәртибенә гомуми таләпләр;

в) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирүнең мәгълүмат системасы.».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында http://buinsk.tatarstan.ru. адресы буенча рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә йөклим.

Буа муниципаль районы Чуаш Киштәге
авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе И.А. Павлов